## Табышмаклар



1. Кар янында күк чәчәк,
Утыра нурлар чәчеп.
Куянның исе киткән:
Бу нинди чәчәк икән?



2. Аны һәркем ярата,
Аның өченҗан ата.
Ул яктырта, улҗылы-
та,
Ул дөньяны яшәтә.

3. Бер гүзәл бар дөньяда,
Гашыйк аңа һәр бала.
Тик бизәнә ул менә
Бары елга бер генә.





4. Елый-елый басып тора:
-Сезгә хезмәт итәм бит,-ди,-
Сезгә якты булсын диеп,
Үзем янып бетәм бит,-ди.



5. Арыш та була,
Бодай да була.
Ул пешсә,өйгә
Татлы ис тула.

## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

1. Минем дусларым: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 16 б. – 25000 д.

2. Ялгыз аккош: шигырьләр, поэмалар, әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 224 б. – 10000 д.

3. Ак песи: әкиятләр. – Казан: Раннур, 2000. – 48 б. – 100000 д.

4. Зәңгәр алан әкияте. – Казан: Раннур, 2000. – 64 б. – 50000 д.

5. Күңелем гөлләре: шигырьләр, җырлар, поэмалар (сайланма әсәрләр). – Казан: Идел-Пресс, 2002. – 416 б. – 3000 д.

6. Кояшлы яңгыр: сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 655 б. – 3000 д.

7. Якты Ярда калган балачак: сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 296 б. – 3000 д.

8. Мактанчык Кот-Кот: әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 62 б. – 3000 д.

9. Сүрелмәс җырым син: шигырьләр, җырлар, поэмалар / кереш сүз авт. Ф.Галимуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 271 б. – 4000 д.




Безнең адрес:
Арча шәһәре,
Банк урамы, 2а йорт

Телефон: 8(4366) 3-21-78
Электронн адрес: cbs_arsk@mail.ru


## Арча район балалар китапханәсе





# Резеда Вәлиева– балалар дусты

**Туган көне :**1930ел , 1нче маенда

**Туган урыны:** Башкортстан Республикасының Кыйгы районы Дүшәмбикә авылы

**Тормыш юлы:** Әтисе Тәфкалүн Хәммәт улы-Россиянең атказанган, ике Ленин орденлы укытучысы, Башкорстанның Салават районы авылларында кырык ел укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләгән, вафаты 1960 елда. Әнисе Мәрзия ханым-башлангыч сыйныфлар укытучысы,1980 елда вафат була.Р.Вәлиева-нигездә балалар язучысы. Аның нәниләр турында язган беренче шигырьләре республика көндәлек матбугатында илленче еллардан күренә башлый, тәүге җыентыгы (“Минем дусларым”) 1960 елда басылып чыга .Резеда Вәлиева 1999 елдан Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем йөртә. 1983 елдан Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булып тора.

(Язучы турында тулырак сез МАТ-BUGAT.RU сайтында укый аласыз)

## Резеда Вәлиеваның бу китапларын сез, безнең китапханәдән алып укый аласыз:




Җыр

## Туган Җирем

*Татлы булса һавалары,*
*Ләззәтле булса җиле,*
*Шифалы булса сулары,*
*Ул– минем туган җирем.*

*Туган җирем, киң Иделем,*
*Казан дигән башкала.*
*Дуслык шунда туа бүген,*
*Бәхет шунда башлана.*

*Кем моңнар, җырлар ярата,*
*Кемнәр ачык күделле,*
*Кем дуслык, туганлык яклы,*
*Әйдә, безгә килегез!*

*Татлы булса һавалары,*
*Ләззәтле булса җиле,*
*Шифалы булса сулары,*
*Ул– минем туган җирем.*